| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Старо-Имянское сельское**<br>**поселение Сармановского**<br>**муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль**<br>**районының Иске Имән**<br>**авыл җирлеге** |

---

| | |
|---|---|
| **КАРАР**<br>**22.11.2024 ел** | **КАРАР**<br>**№112** |

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нче еллар план чорына социаль-икътисадый үсеше фаразы турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нчы еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында» гы мәгълүматны тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нчы еллар планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).
2. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты Иске Имән авыл җирлегенең 2025 нче елга һәм 2026-2027 нчы еллар планлы чорына социаль-икътисади үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә тиеш.
3. Әлеге карарны контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова

1 кушымта

**Социаль-икътисадый үсеш фаразы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2025 елга һәм 2026-2027 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы**

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хисап | Хисап | Бәя | Фараз | Фараз | Фараз |
| Халык саны | чел. | 452 | 450 | 448 | 446 | 444 | 442 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 0,01 | -0,01 | -0,01 | -0,01 | -0,01 | -0,01 |
| Эре мөгезле терлекләр саны | баш | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | - | +1,03 | - | - | - | - |
| Инвестицияләр | мен. сум. | - | - | - | - | - | - |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | - | - | - | - | - | - |
| Торак тапшыру | кв.м. | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Узган елга карата үсеш темпы | % | - | - | - | - | - | - |
| Хезмәт өчен түләү фонды | мең. сум. | 11897,3 | 14812,2 | 16752,6 | 18411,2 | 20160,2 | 22115,7 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Узган елга карата үсеш темпы | % | 1,15 | 1,24 | 1,13 | 1,09 | 1,09 | 1,09 |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум. | 41310,1 | 51431,2 | 58168,8 | 63927,4 | 70000,7 | 76790,6 |
| Уртача эшләүчеләр саны | кеше | 24 | 24 | 24 | 24 | 24 | 24 |
| Эшмәкәрләр саны (КФХ)) | кеше | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| Эшсезләр саны | кеше | - | - | - | - | - | - |

Иске Имән авыл җирлеге бухгалтеры: Шайхетдинова Г.Н.

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026-2027 елларның план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразына аңлатма

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразына керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнарының статьяларын формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала. 2025-2027 елларда Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы 2025-2026 елларга Россия Федерациясе икътисады эшчәнлегенен сценар шартларының база варианты нигезендә, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән, Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2024 ел нәтиҗәләрен һәм 2025-2026 елларда икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләрен бәяләүне исәпкә алып, 2025-2027 елларга Россия Икътисадый үсеш министрлыгы тәкъдим иткән инфляция һәм индекс-дефляторлар күрсәткечләрен кулланып эшләнгән.

2025-2027 еллардада «Urals» нефтькә бәянең уртача динамикасы баррель өчен 69,5-65,9 дәрәҗәсендә фаразлана. 2025 елда доллар курсы уртача еллык АКШ доллары өчен 96,5 сум, 2026 елда АКШ доллары өчен 100 сум булыр дип фаразлана. 2027 елда, Россия Икътисадый үсеш министрлыгы фаразына караганда, доллар курсы АКШ доллары өчен 100 сум тәшкил итәчәк.

Иске Имән авыл җирлеге 2 торак пункттан тора: Иске Имән, Сарысаз Тәкермән авыллары. 2025 елга Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегендә халык саны 446 кеше, 2026 елга 444, 2027 елга 442 кеше тәшкил итәчәк. Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Агрокөч төркеме», фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларның потенциалын һәм бүгенге үсеш тенденцияләрен, шулай ук «агросәнәгать комплексын үстерү «шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» программаларын гамәлгә ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнгән.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә, "Газизов" КФХ, "Газизова "КФХ, “Бурганов” “КФХ” эшчәнлеге алып бара.

Хезмәткәрләр саны уртача 24 кеше тәшкил итә.

2024-2026 елларда якынча 300 кв. м торак файдалануга тапшыру планлаштырыла.

Хезмәт өчен түләү фонды 2025 елда 18411,1 мең сум, 2026 елда 20160,2 мең сум, 2027 елда 22115,7 мең сум тәшкил итәчәк.

Уртача хезмәт хакы 2026елда 62927,4 сум тәшкил итәчәк. 2026 елга фараз буенча ул 70000,7 сум, 2027 елда – 76790,6 сум тәшкил итәчәк.

2025 елга эшмәкәрләр саны 18 кеше, 2026 елга 19, 2026 елга 20 кеше тәшкил итәчәк.